ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 12 2024 г. № 1376

«Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр түләүсез туклandыруны оештыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 956 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны социаль яклау максатларында һәм кулланучылар бәяләре үсешен индексацияләүгә бәйле рәвештә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында яшәмәгән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай туклandыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2024 елның 9 сентябрендәге 950 номерлы Татарстан Республикасы Башкарма комитеты карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарда бирелгән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Кушымта
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
«25» 12 2024 № 1376

Кушымта № 2
Расланган
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән
30 декабрь 2022 ел № 956

## Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында балаларның түбәндәге категорияләре өчен туклану бәясе

| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1-4 сыйныфларда 2 тапкыр туклану | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум. | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| Шәһәр, авыл һәм Кама Аланы | 126,99 | 57,56 | 29,16 | 40,27 |
| 5-11 сыйныфларда 2 тапкыр туклану/1 тапкыр туклану | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум.. | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| Шәһәр, авыл һәм Кама Аланы | 131,90 | 122,30 | 9,60 | - |